**Яр Чаллы шәһәре Хакиме**
**карары**

**№М 604**
**20.12.2023**

Шәһәр Хакименең 2014 елның 21 ноябрендәге М 692 номерлы Карары белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәтнең гражданнар вазыйфага билгеләнгәндә керемнәре турында, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре турында, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар бирергә бурычлы булган һәм Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләр вазыйфа биләгәндә керемнәре, чыгымнары турында, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары турында, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар бирергә бурычлы булган вазыйфалар исемлегенә үзгәреш кертү турында

Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы Карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.24 пункты нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Шәһәр Хакименең «Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәре турында, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар, шулай ук Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан керемнәре, чыгымнары турында, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар бирү турында нигезләмәне раслау хакында» 2014 елның 21 ноябрендәге М 692 номерлы Карары (Шәһәр Хакименең 2015 елның 24 февралендәге М 58 номерлы, 2016 елның

1 февралендәге М 34 номерлы, 2018 елның 29 июнендәге М 293 номерлы, 2021 елның 14 маендагы М 186 номерлы, 2022 елның 14 мартындагы М 94 номерлы, 2022 елның 17 июнендәге М 254 номерлы, 2022 елның 2 ноябрендәге М 484 номерлы, 2023 елның 24 мартындагы М 113 номерлы, 2023 елның 3 октябрендәге М 454 номерлы Карарлары редакциясендә) белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәтнең гражданнар вазыйфага билгеләнгәндә керемнәре турында, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре турында, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар бирергә бурычлы булган һәм Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләр вазыйфа биләгәндә керемнәре, чыгымнары турында, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары турында, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар бирергә бурычлы булган вазыйфалар исемлегенә, 2 пунктка түбәндәге эчтәлектәге 37 пунктча өстәп, үзгәреш кертергә:

«37) Башкарма комитет икътисадый үсеш һәм эшмәкәрлеккә ярдәм күрсәтү идарәсенең кулланучылар базары бүлеге башлыгы.».

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе Ф.Ш. Салаховка йөкләргә.

Шәһәр Хакиме Н.Г. Мәһдиев